# КАРАР

**15 ноябрь 2021 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, җыен 15 ноябрь 2021 елда утте:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 4000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Лесная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- Хасановка авылында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.

- скважина бораулау, материал, җиһазлар сатып алу, колонка урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру).

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 5 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. 2021 елда үзара салым суммасын 4300 сумга кадәр арттырырга, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә:

- урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- скважина бораулау, материал, җиһазлар сатып алу, кое төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелек)

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгләмова